**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

**КАРАР**
IV чакырылыш чираттан тыш утырышы

2020 елның 16 декабре № 25 Урыссу ш.т.п.

**2016 елның 16 декабрендә Татарстан Республикасы Ютазы район Советының №33 карары белән кабул ителгән "2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәр планлы чорга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше стратегиясен” яңа редакциядә раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында» 28.06.2014 ел, № 172-ФЗ Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, «Татарстан Республикасында стратегик планлаштыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 12-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2020 елның 28 апрелендәге 18 номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставына нигезләнеп һәм социаль-икътисадый сорауларны комплекслы хәл итү, халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының производство һәм инвестицион потенциалын үстерү максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2016 ел, 16 декабрь, №33 карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының 2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге план чорына социаль-икътисадый үсеш стратегиясен» әлеге карарга кушымтага ярашлы рәвештә, яңа редакциядә расларга.
2. «Татарстан Республикасы Ютазы район Советының “2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге план чорына Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше стратегиясен раслау турында " 2020 ел, 26 май, №23 карары үз көчен югалткан дип санарга.
3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Ютазы

муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Ютазы районы Советының бюджет, салымнар, инвестицияләр һәм эшкуарлык буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Ютазы муниципаль районы**
**Башлыгы – Татартсан Республикасы**
**Ютазы районы Советы Рәисе** **А. Ә. Шәфигуллин**